Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«11» ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 11 ноябрендә узган: «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм вак таш түшәү;

- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү»

- Фома авылының Мәктәп урамы буенча ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 490 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 299 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 250 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 49 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге Фома авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлегенең Фома авылы территориясендә яшәүче балигъ булган, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм вак таш түшәү;

- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү»

- Фома авылының Мәктәп урамы буенча ял итү зоналарын булдыру һәм төзекләндерү» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеге Фома авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Фома авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Х.Абдрахманов

Фома авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Абдрахманов